Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль район Советының унынчы утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

20 май, 2021 ел № 73

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында муниципаль вазыйфаны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе хакында нигезләмәне раслау турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 12.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 26 июлендәге 251-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 24 апрелендәге 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Муниципаль вазыйфа я контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы нигезендә һәм «Муниципаль вазыйфа я контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны я контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы һәм Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәшне координацияләү буенча комиссия утырышы беркетмәсенең 5.1 пунктын үтәү өчен, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы белән **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында муниципаль вазыйфа биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт

турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында кушымтада бирелгән Нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының җирле үзидарә органнарына үз эшчәнлекләрендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында муниципаль вазыйфаны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан әлеге карар белән расланган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе хакындагы нигезләмәгә таянырга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карары белән расланды
20 май, 2021 ел № 73

**Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында муниципаль вазыйфаны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру турында нигезләмә**

## I. Әлеге Нигезләмәне җайга салу предметы

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында муниципаль вазыйфаны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибен билгели.

2. Әлеге Нигезләмә муниципаль вазыйфаны биләүне дәгъвалаучы, авыл җирлеге вәкиллекле органы депутаты һәм муниципаль вазыйфаны биләүче һәм авыл җирлегенең вәкиллекле органы депутаты вазыйфасын биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр бирүгә бәйле мөнәсәбәтләргә кагыла.

## II. Керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшыру тәртибе һәм сроклары

1. Авыл җирлеге вәкиллекле органы депутатының муниципаль вазыйфасын биләүче һәм даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы зат Татарстан Республикасы Президентына Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртиптә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, депутат сайлаган көннән алып дүрт ай эчендә, аңа вакантлы депутат мандатын тапшырган яисә даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны туктаткан көннән алып дүрт ай эчендә, шулай ук законнар нигезендә расланган белешмәләр (хисап чоры) бирелгән елдан алдагы һәр ел эчендә, 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган алыш-бирешләр чоры дәвамында башкарылган очракта, хисап чоры формасында белешмәләр тапшыру турында белешмәләр тапшыра.

2. II бүлекнең 1 пунктында каралган белешмә «БК белешмәләре» махсус программа тәэмин ителешен кулланып тутырыла. Күрсәтелгән белешмәнең күчермәсе авыл җирлеге вәкиллекле органы депутаты муниципаль вазыйфасын биләүче һәм даими нигездә үз вәкаләтләрен башкаручы зат тарафыннан имзаланган

кәгазь чыганакта, Питрәч муниципаль районында коррупция бозуларны профилактикалау буенча вәкаләтле вазыйфаи затка җибәрелә һәм законнар нигезендә сакланырга тиеш.

3. Хисап чорында мондый алыш-бирешләр башкарылмаган очракта, авыл җирлеге вәкиллекле органы депутаты муниципаль вазыйфасын биләүче һәм даими булмаган нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы зат бу хакта Татарстан Республикасы Президентына, әлеге Нигезләмәгә кушымта нигезендә махсуслаштырылган мәгълүмат ресурсыннан файдаланып, керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү өчен (dohod.tatar.ru) әлеге Нигезләмәгә кушымта буенча хәбәрнамә җибәрү юлы белән хәбәр итә.

4. II бүлекнең 3 пунктында каралган белешмәләр, шулай ук II бүлекнең 1 пункты белән (дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә караган башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган алыш-бирешләрнең хисап чоры дәвамында башкарылган очракта) белешмәләр Татарстан Республикасы граждан хезмәткәрләре керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән срокта бирелә.

5. Кандидатның керемнәре күләме һәм чыганаклары турында, шулай ук кандидатның милек хокукында (шул исәптән уртак милек) булган мөлкәте турында, банклардагы кертемнәре, кыйммәтле кәгазьләре турында, цифрлы финанс активлары турында, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә цифрлы валюта турында белешмәләр тапшыру аны депутат вазыйфасына 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 4.2 өлешендә каралган белешмәләрне тәкъдим итү бурычыннан азат итми.

6. 230-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне депутат булып сайланган яисә вакантлы депутат мандатын тапшырган көннән алып дүрт ай эчендә тапшырганда, аларга чыгымнар турында белешмәләр бирелми.

7. Депутат булып сайланган яисә вакантлы депутат мандатын тапшырган көннән соң күрсәтелгән дүрт айлык срок сайлау комиссиясе тиешле карар кабул иткән көннән исәпләнә башлый.

8. Депутат булып сайланган, вакантлы депутат мандатын тапшырган яисә даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру туктатылган көннән алып дүрт ай эчендә белешмәләр тапшырганда депутат түбәндәгеләр тапшыра:

- белешмәләр бирү елыннан алдагы календарь ел өчен барлык чыганаклардан алынган керемнәре, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, керемнәре турында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр), шулай ук күчемсез мөлкәт, транспорт чаралары һәм кыйммәтле кәгазьләр, цифрлы финанс активлары, түләүсез алыш-биреш нәтиҗәсендә шушы период дәвамында читләштерелгән цифрлы валюта турында белешмәләр;

- Милек хокукында аның, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының мөлкәте турында белешмәләр, банклардагы һәм башка кредит

оешмаларындагы счетлары, кыйммәтле кәгазьләр, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта, белешмәләр биргән айга кадәрге айның беренче числосына булган мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр.

9. 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган алыш-бирешләр башкарылуга бәйле рәвештә тапшырыла торган белешмәләр әлеге алыш-бирешләрне башкару елыннан соңгы елның 1 гыйнварыннан 1 апреленә кадәр депутат булып тапшырылырга тиеш.

Бу чакта күрсәтелгән алыш-бирешләргә түбәндәгеләр керми:

- никахлашуга кадәр әлеге затның хатыны (ире) тарафыннан кылынган килешүләр;

- авыл җирлегенең вәкиллекле органы депутаты муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүгә кадәр зат тарафыннан кылынган алыш-бирешләр, өстәвенә, башта 230-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында санап үтелгән вазыйфаларны затның яисә аның хатынының (иренең) элек биләмәве.

## III. Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында төгәлләштерелгән белешмәләр тапшыру

1. Муниципаль вазыйфаны авыл җирлеге вәкиллекле органы депутаты вазыйфасын биләүче һәм даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы зат күрсәтелгән белешмәләрдә керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында алар биргән белешмәләрдә законнарда каралган тәртиптә күрсәтелмәгән яисә нинди дә булса белешмәләр күрсәтелмәгән яисә ялгышлар булган очракта, ул Татарстан Республикасы Президентына керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында төгәлләштерелгән белешмәләрне (алга таба - төгәлләштерелгән белешмәләр) тапшыра.

## IV. Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне тапшырмаган йә белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен җаваплылык.

1. «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәүне депутат вәкаләтләре вакытыннан алда туктатуга китерә.

2. Муниципаль вазыйфаны авыл җирлеге вәкиллекле органы депутаты вазыйфасын биләүче һәм даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы зат тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырылмаган очракта, ул Федераль законнарда, Россия Федерациясе субъектлары законнарында, муниципаль норматив хокукый актларда каралган тәртиптә ышанычны югалтуга бәйле рәвештә вазыйфасыннан азат ителергә тиеш.

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында нигезләмәгә кушымта
«20» май, 2021 ел № 73 ___

**Татарстан Республикасы Президентына**

________________________________

**Хәбәрнамә**

Мин, _____________________ муниципаль районы ______________ авыл
*муниципаль район исеме* *авыл җирлегенең вәкиллекле органы исеме*
җирлеге депутаты ________________________________________________,
фамилиясе, исеме һәм (булса) атасының исеме
«___»________________, _ _ ________ _________________________________________,
туган елы паспорт сериясе бирү датасы һәм паспорт биргән орган

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 121 статьясындагы 4.2 өлеше һәм «Муниципаль вазифага яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасына дәгъвалаучы гражданнарның, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын яисә җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 4.1 өлеше нигезендә, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган килешүләр (җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлешләре, пайлары), санлы финанс активлары, санлы валюта, гомуми күләме (минем һәм хатыным (ирем) кеременнән артып киткән соңгы өч елда, хисап чорына кадәр) хисап чоры дәвамында 1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр эшләмәде.

Әлеге белешмәләрнең дөреслеген раслыйм.
«___»___________ 20____ел
________________________________
*гариза биргән зат имзасы*
____________________________________________________
*(хәбәрнамәне кабул итүгә вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм (булса) атасының исеме һәм имзасы)*